КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 8 апрель г.Казань № 238

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәренең мәдәни катламын истәлекле урыны рәвешендә төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына кертү турында» 2010 ел, 15 февраль, 79 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәренең мәдәни катламын истәлекле урыны рәвешендә төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына кертү турында» 2010 ел, 15 февраль, 79 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 ел, 30 сентябрь, 774 нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «(республика)» сүзен төшереп калдырырга;

1 пунктта:

беренче абзацта «(республика)» сүзен төшереп калдырырга;

икенче абзацта «1 нче һәм 2 нче кушымталар нигезендә чикләрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

өченче абзацта «3 нче һәм 4 нче кушымталар нигезендә чикләрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

дүртенче абзацта «5 нче һәм 6 нчы кушымталар нигезендә чикләрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

бишенче абзацта «7 нче һәм 8 нче кушымталар нигезендә чикләрдә» сүзләрен төшереп калдырырга;

2 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

әлеге карарга теркәлгән 1 - 8 нче кушымталар үз көчен югалткан дип танырга;

3 пунктта «Татарстан Республикасының Мәдәният министрлыгына» сүзләрен «Татарстан Республикасының Мәдәни мирас объектларын саклау комитеты» сүзләренә алмаштырырга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Казан шәһәренең мәдәни катламын истәлекле урыны рәвешендә төбәк (республика) әһәмиятендәге мәдәни мирас объектларына кертү турында» 2010 ел, 15 февраль, 79 нчы карарына үзгәрешләр кертү турында 2010 ел, 30 сентябрь, 774 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин